# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Кече Мәми авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

20 нче ноябрь 2020 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 17 нче ноябрендә 14 сәгатьтә, 2020 елның 20 нче ноябрендә 14 сәгатьтә этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- материаллар сатып алып мемориалны төзекләндерү;
- су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (проект нигезендә скважиналар һәм санитар саклау зоналарын төзү, су анализы, "санитар саклау зоналары" һәм "эчә торган су" СанПиН нормаларына экспертиза үткерү, гигиена һәм эпидемиология үзәге" федераль бюджет сәламәтлек саклау учреҗдениесендә санитария-эпидемиалогия бәяләмәсе алу һәм санитария-эпидемиалогия бәяләмәсе алу һәм башка документлар алу);
- артезиан скважинасын тирәнәйтү буенча эш;
- материаллар сатып алып тирән насосны алыштыру;
- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;
- Кече Мәми авылы территориясен чистарту һәм үләнне чаптыру.

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 260 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -152, бу 58,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 152 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең Кече Мәми авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.«Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- материаллар сатып алып мемориалны төзекләндерү;

су алу скважиналарын лицензияләү буенча әзерлек эшләре (проект нигезендә скважиналар һәм санитар саклау зоналарын төзү, су анализы, "санитар саклау зоналары" һәм "эчә торган су" СанПиН нормаларына экспертиза үткерү, гигиена һәм эпидемиология үзәге" федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесендә санитария-эпидемиалогия бәяләмәсе алу һәм санитария-эпидемиалогия бәяләмәсе алу һәм башка документлар алу);

- артезиан скважинасын тирәнәйтү буенча эш;
- материаллар сатып алып тирән насосны алыштыру;
- материаллар сатып алып юлларны норматив хәлгә китерү;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;
- Кече Мәми авылы территориясен чистарту һәм үләнне чаптыру.

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлегенең Кече Мәми торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2020 елның 20 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы Е.Н.Алексеева